**СОВЕТ НИКОЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422627 с. Никольское,
ул. Центральная, д.35
тел: 4-31-44

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ НИКОЛЬСКИЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422627 Никольский авылы,
Үзәк урамы, 35 нчы йорт,
тел: 4-31-44

---

**№ 7** **2019 елның 24 апреленнән**

**КАРАР**

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Николький авыл җирлеге Башкарма комитеты баш бухгалтерларының (муниципаль хезмәткәрләр вазифаларына караган вазифалардан тыш) хезмәтенә түләү шартлары һәм оештыру турында**

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Никольский авыл җирлеге Советы карар бирә:

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Никольский авыл җирлеге Башкарма комитеты баш бухгалтерларының (муниципаль хезмәткәрләр вазифаларына караган вазифалардан тыш) хезмәтенә түләү шартлары һәм оештыру турындагы кушып бирелүче Кагыйдәне расларга.

1. Хезмәткәрләрнең әлеге карарга ярашлы төстә билгеләнгән хезмәт хакы күләме, хезмәткәрләрнең вазифаи бурычлары күләме сакланганда һәм алар тарафыннан шул ук квалификация эшләре башкарылганда, 2019 елның 31 мартына түләнгән хезмәт хакы күләменнән кимрәк була алмый.

2. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Никольский авыл җирлеге Советының 2018 елның16 апреленнән №8 “Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Никольский авыл җирлегенең бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәтенә түләү буенча Бердәм сеткага кермәгән бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турында”гы карарын көчен югалткан дип табарга.

3. Бу карарның гамәлдә булуы 2019 елның 1 апреленә булган хокук мөнәсәбәтләренә кагылуын билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Никольский авыл җирлеге Башкарма комитеты баш бухгалтерларының (муниципаль хезмәткәрләр вазифаларына караган вазифалардан тыш) вазифалары исемен әлеге карарга ярашлы төстә бирүне тәэмин итәргә.

5. Әлеге карар үтәлешенә контрольлек итүне муниципаль районның Никольский авыл җирлеге Советының план-бюджет һәм икътисади үсеш комиссиясенә йөкләргә.

**Башлык - Лаеш муниципаль районы**
**Никольский авыл җирлеге**
**Советы рәисе** **Э.Х.Алеев**